**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ГЛАВА**
**Сарлинского сельского поселения**
**Азнакаевского муниципального района**

ул. Центральная, д. 68А, село Сарлы,
Азнакаевского муниципального района, 423315
Тел. 36-5-34

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы**
**Сарлы авыл жирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 68А, Сарлы авылы
Азнакай муниципаль районы, 423315
Тел. 36-5-34


# ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

«04» июнь 2020 ел — № 2

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 28 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә халык алдында тыңлаулар оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәгә таянып карар итәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге Советының 2014 елның 23 гыйнварындагы 54-3 нче номерлы карары белән расланган (21.11.2014 №70-37, 21.11.2016 №40-24, 04.09.2017 №60-32, 02.07.2018 №99-51, 19.03.2019 №127-64, 19.02.2020 №157-77 карарлар редакциясендә), Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы "Сарлы авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

1.1. Шәһәр төзелешен зоналаштыру картасында

- ТР, Азнакай муниципаль районы, Сарлы авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:02:100204:44 кадастр номерлы җир кишәрлегеөчен территориаль зонаны СН2 махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасыннан СХ1 авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасына үзгәртергә.

2. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссияне ачык тыңлауларны оештыручы итеп;

- үткәрү вакыты-2020 елның 5 июленнән 2020 елның 07 августына, 17.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

- үткәрүурыны-Сарлыавылы, Үзәкур., 68А;

- 2020 елның 7 августына кадәр фикер алышына торган мәсьәлә буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр кертелә торган адрес: Сарлы авылы, Үзәк урамы, 68А йорт, Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлеге башкарма комитеты.

4. Азнакай муниципаль районы Сарлы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча комиссиягә:

- Азнакай муниципаль районы «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проекты буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге карар белән билгеләнгән срокларда ачык тыңлаулар әзерләргә һәм үткәрергә;

- ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәләре турында бәяләмә әзерләргә һәм аны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга;

- Азнакай муниципаль районының «Сарлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү проектын Азнакай муниципаль районының Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo. tatarstan.ru.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.




Башлык М.Р.Шәрипов